**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**СЮНДЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422396 с. Сюндюково, ул. Такташа, 15

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СӨЕНДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422396 Сөендек авылы, Такташ урамы, 15

тел. (84373) 5-07-27, факс 5-07-27, e-mail: ssundukovo@mail.ru
ОГРН 1021606557136, ИНН/КПП 1638001663/163801001

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 .11. 2023** **№ 31-1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проекты турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Сөендек авыл җирлеге Советына таянып карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының тәкъдим ителгән проектын (алга таба – Устав проекты) беренче укылышта 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Устав проекты буенча комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Устав проектын тикшерүдә гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 3 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Устав проектын тикшерүдә гражданнарның катнашу тәртибен 4 нче кушымта нигезендә расларга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Сөендек авылы, Тукай урамы, 14 йорт; Вожжи авылы, Үзәк урам, 28 йорт торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru.
7. Устав проекты буенча 2023 елның 22 декабрендә 14:00 сәгатьтә Сөендек авыл мәдәният йорты бинасында ачык тыңлаулар билгеләргә.
8. Устав проекты буенча Комиссиягә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә ачык тыңлаулар турындагы нигезләмәгә ярашлы рәвештә Устав проектын тикшерү һәм килгән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.
9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Сөендек авыл җирлеге башлыгы Х.Ә. Измайловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Х.А. Измайлов**